**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2021 № 62

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ботакларны кисеп формалаштыруга, яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә,ботакларны кисеп формалаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«(2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А.М. Шәрәфиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин